**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 186**
**14.05.2021**

Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә, Башкарма комитетның штат расписаниесе үзгәрү сәбәпле

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына (Шәһәр Хакименең 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы, 2016 елның 1 февралендәге М 34 номерлы, 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәдә:

а) 6 пунктның «в» пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«в) әгәр мондый килешүләрнең (мондый килешүнең) гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, җир участогы, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәрге хисап чорында) сатып алу буенча һәр килешү буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм гамәлгә ашырылган килешүләр (гамәлгә ашырылган килешү) өчен алынган акча чыганаклары турындагы мәгълүматлар).»;

б) 9 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Граждан һәм муниципаль хезмәткәр кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгечкә) үзләре биргән мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган яисә хаталар булуны ачыклаган очракта, алар әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә аныкланган мәгълүматларны бирергә хокуклы.

Граждан аныкланган мәгълүматларны, әлеге нигезләмәнең 3 пункты нигезендә мәгълүматлар бирелгән көннән башлап бер ай эчендә бирергә мөмкин.

Муниципаль хезмәткәр аныкланган мәгълүматларны, әлеге нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән башлап бер ай эчендә бирергә мөмкин.»;

в) 13 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«13. Мондый килешүләрнең (мондый килешүнең) гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук җир участогы, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлары), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәрге хисап чорында) сатып алу буенча гамәлгә ашырылган килешүләр (гамәлгә ашырылган килешү) өчен алынган акча чыганаклары турында мәгълүматлар законда билгеләнгән тәртиптә «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына урнаштырыла, ә әлеге мәгълүматлар «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында булмаган очракта, массакүләм мәгълүмат чараларының запрослары буенча, бастырып чыгару өчен аларга тапшырыла.»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенең 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәтнең, аны биләгәндә коррупция куркынычы белән бәйле

булган һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр нигезендә хакимият вәкиле функцияләрен яисә оештыру-боеру яки административ-хуҗалык функцияләрен гамәлгә ашыруны; гражданнарга һәм оешмаларга муниципаль хезмәтләр күрсәтүне; контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыруны; бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлеп бирү турындагы карарлар әзерләү һәм кабул итүне, шулай ук чикле ресурсларны бүлеп бирүне; дәүләт мөлкәте белән идарә итүне; муниципаль сатып алуларны яисә лицензияләр һәм рөхсәт кәгазьләрен бирүне гамәлгә ашыруны; материаль-техник ресурсларны саклау һәм бүлеп бирүне күздә тота торган башка вазыйфалары:

1) Хаким ярдәмчесе;

2) Башкарма комитет Җитәкчесе ярдәмчесе;

3) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең исәпкә алу һәм мөлкәт белән идарә итү бүлеге башлыгы;

4) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җиргә кагылышлы аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы;

5) Башкарма комитет архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәтләр бирү бүлеге башлыгы;

6) Башкарма комитет архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең архитектура, дизайн һәм реклама бүлеге башлыгы;

7) Башкарма комитет районнар хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгы;

8) Башкарма комитет административ-техник инспекция идарәсенең җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлеге башлыгы;

9) Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсенең район җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы;

10) Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү бүлегенең баш белгече;

11) Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе транспорт һәм элемтә бүлегенең баш белгече;

12) Башкарма комитет алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясен үстерү бүлегенең баш белгече;

13) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең исәпкә алу һәм мөлкәт белән идарә итү бүлегенең баш белгече;

14) Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җиргә кагылышлы аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлегенең баш белгече;

15) Башкарма комитет финанс идарәсе бюджет бүлегенең баш белгече;

16) Башкарма комитет архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәтләр бирү бүлегенең баш белгече;

17) Башкарма комитет архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең архитектура, дизайн һәм реклама бүлегенең баш белгече;

18) Башкарма комитетның районнар хакимияте торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү бүлегенең баш белгече;

19) Башкарма комитетның районнар хакимияте территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлегенең баш белгече;

20) Башкарма комитет карамагындагы күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өлкәсендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеге бүлегенең баш белгече;

21) Башкарма комитет административ-техник инспекция идарәсенең баш белгече;

22) Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлегенең баш белгече;

23) Башкарма комитет архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәтләр бирү бүлегенең әйдәүче белгече;

24) Башкарма комитетның районнар хакимияте торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү, территориаль иҗтимагый үзидарәне үстерү бүлегенең әйдәүче белгече;

25) Башкарма комитетның районнар хакимияте территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлегенең әйдәүче белгече;

26) Башкарма комитет административ-техник инспекция идарәсенең әйдәүче белгече;

27) Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе җирдән файдалануны һәм яшел утыртмалар сакланышын контрольдә тоту бүлегенең әйдәүче белгече;

28) Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе район җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (торак секторда хокук бозуларны профилактикалау һәм индивидуаль профилактик йогынты чараларын куллану буенча инспектор);

29) Башкарма комитет карамагындагы җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү идарәсе район җәмәгать тәртибен саклау бүлегенең әйдәүче белгече (гаиләнең имин булмавын һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча инспектор);

30) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Контроль-хисап палатасының әйдәүче инспекторы;

31) Башкарма комитет административ-техник инспекция идарәсенең 1 категорияле белгече.»;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә www.nabchelny.ru Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына урнаштыру турында һәм бастырып чыгару өчен әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәнең 3 пунктының 4 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4) әгәр мондый килешүләрнең (мондый килешүнең) гомуми суммасы муниципаль хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, җир участогы, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча гамәлгә ашырылган килешүләр (гамәлгә ашырылган килешү) өчен алынган акча чыганаклары турында мәгълүматлар.»;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында вазыйфалар исемлегенә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларны Интернет челтәрендә

www.nabchelny.ru Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтына урнаштыру турында һәм бастырып чыгару өчен әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү турында нигезләмәгә кушымтада «улы», «кызы» сүзләрен «балигъ булмаган бала» сүзләренә алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 13 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев